**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7,
Черемшан село, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы,
423100

тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**№ 149** **2018 ел** **16 ноябрь**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советының
2018 елның 29 августындагы 138 нче
«Физик затларның милкенә салым турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

КАРАРЫ

2018 елның 3 августында кабул ителгән 334-ФЗ номерлы " Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешнең 52 статьясына »үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 августында кабул ителгән 138 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 16 октябрендәге 12 номерлы, 2018 елның 26 апрелендәге 126 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

* 2 пунктның 1 пунктчасындагы 1 абзацында «фатирлар» сүзеннән соң: «фатир өлешләре» дип тулыландырырга;

2 пунктның 1 пунктчасында «торак йортлар» сүзеннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «торак йортларның бер өлеше».

• 3 пункт түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:

• "18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләргә салым түләүдән азат итеп, ташлама бирергә".

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар «Безнең Чирмешән» район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыкканнан соң (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырганнан соң законлы көченә керә.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советы
рәисе вызыйфасын башкаручы
урынбасары М.В. Кандрова